| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br><br>**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**<br>**Алькеевского**<br>**муниципального района** | | **ТАТАРСТАН**<br>**РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>**Әлки**<br>**муниципаль районы**<br>**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Базарлы Матак авылы **КАРАР**

2022 елның 25 ноябре 429№

Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 23 апрелендәге « Әлки муниципаль районында үзәкләштерелгән хисап җитәкчеләре һәм белгечләренең, муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетларының баш хисапчылары һәм хисапчылары (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәте өчен түләү оештыру һәм шартлары турында» 164 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Әлки муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмаучы аерым бюджет оешмаларының үзәкләштерелгән бухгалтерияләре хезмәткәрләренә социаль гарантияләрне тәэмин итү һәм хезмәт өчен түләүне тәртипкә салу максатларында, Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 23 апрелендәге « Әлки муниципаль районында үзәкләштерелгән хисап җитәкчеләре һәм белгечләренең, муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетларының баш хисапчылары һәм хисапчылары (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәте өчен түләү оештыру һәм шартлары турында» 164 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Әлки муниципаль районында “Әлки районы мәдәният бүлеге” МКУ һәм “ ТР Әлки муниципаль районы мәгариф идарәсе” МКУ җитәкчеләре һәм белгечләренең хезмәт хакын оештыру һәм аларны түләү шартлары турында нигезләмәнең 2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2. «Әлки район мәдәният бүлеге» МКУ һәм «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Җитәкче һәм белгеч вазыйфасы | Вазыйфаи оклад, сум | |
|---|---|---|
| | Муниципаль учреждение булып торучы үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен | Башкарма комитетның (башка җирле үзидарә органы) структур бүлекчәсе (бүлеге) булып торган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе | 27 700 | |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары | 25 500 | |
| Башкарма комитетның структур бүлекчә җитәкчесе (баш хисапчы) | | 25 500 |
| Бүлек начальнигы | 21 700 | 21 700 |
| Әйдәп баручы хисапчы | 19 300 | 19 300 |
| Хисапчы | 18 000 | 18 000 |

2) Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының баш хисапчылары һәм хисапчыларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт өчен түләүне оештыру һәм шартлары турындагы нигезләмәнең 3 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«3. Хисапчыларның вазыйфаи окладлары түбәндәге үлчәмнәрдә билгеләнә:

| Вазыйфа | Муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетларындагы халык саны | |
|---|---|---|
| | 3,5 меңгә кадәр кеше | 3,5 меңнән артык кеше |
| Баш хисапчы | 19 700 | 21 000 |
| Хисапчы | | 18 500 |

2. «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУ әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны билгеләнгән тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлки муниципаль районының авыл җирлекләре җитәкчеләренә элек чыгарылган актларны әлеге карарга туры китерергә.

4. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе Р.Х.Морадымов

Билалова А.А.
88434621726